ҖОМГА
2
АПРЕЛЬ
1943 ел.
№ 72 (6794)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ГЕРОЙ ШӘҺӘР ТАГЫН ДА ЧӘЧӘК АТАР

Идел буе байлыкларын талап алып, Москвага һөҗүм ясау теләге белән Сталинградка килгән гитлерчы илбасарлар Сталинград янында үзләренә кабер таптылар. Данлыклы Кызыл Армиябезнең герой сугышчылары һәм командирлары бандитлар өерен көнбатышка алып ташладылар һәм Сталинград җирен немец кабахәтләрдән бөтенләйгә чистарттылар. Сталинград азат ителде. Ул яңадан тормышка кайтарыла.

Хәзер Идел буендагы бу герой шәһәр, авыр сугышлардан соң, немец ерткычлар тарафыннан җимерелгән һәм бөлгенлеккә төшерелгән хуҗалыгын яңадан аякка бастыру һәм үзенең авыр яраларын төзәтү эшенә керешә. Бу тарихи көрәштә мәңгелек дан казанган Сталинград һәрбер совет кешесенең йөрәгенә якын, кадерле. Шуңа күрә дә аны аякка бастыру эшенә барлык халык, бөтен ил катнаша.

Сталинград шәһәрен һәм аның районнарын аякка бастыруда ярдәм итү хәрәкәте безнең орденлы Татарстан республикасы хезмәт ияләре арасында да киң колач белән җәелә. Республикабызның хезмәт ияләре Сталинград шәһәренең Дзержинский районын һәм өлкәнең Городищенский, Красноармейский районнарын шефка алдылар. Хәзер бездә шушы районнарның халык хуҗалыгын аякка бастыру өчен кирәк булган барлык чаралар күрелә.

Безнең колхозчыларыбыз шефтагы районнарга җибәрү өчен терлекчелек фермалары оештыралар, чәчүлек орлыклар җыялар, авыл хуҗалыгы өчен кирәк булган инвентарьны әзерлиләр. Эшчеләр һәм инженер-техник работниклар эш сәгатьләреннән тыш калып Сталинград предприятиеләрен җиһазлау өчен станоклар, инструментлар һәм запас частьлар ясыйлар. Азат ителгән туганнарыбыз өчен йорт кирәк-яраклары, кием-салымнар, уку әсбаблары, культура җиһазлары һәм башка нәрсәләр җыю эше дә киң күләмдә башланып китте. Бу эш хәзер барлык халык эше булып әверелде.

Партбюро секретаре урынбасары иптәш Закиров булган Н-че завод коллективы гына да Сталинградка 6 вагон төзү материаллары, күп кенә инструментлар, станоклар һәм башка төрле җиһазлар җибәрә. Коллектив бер районда көтепханә оештыру өчен 3.000 данә китап җыйды. Сталинградка ярдәм фондына 100.000 сум акча туплап тапшырды. Заводның тәэминат бүлеге 3.000 данә чиләк, тагарак, балалар ванналары һәм башка әйберләр җибәрә. Шушылар өстенә завод 100 урынлы бер балалар бакчасын йомшак мебельләр белән җиһазлый. Югары квалификацияле эшчеләрдән бригадир Шипков, слесарьлардан Прокофьев, Пупанов, сварщик Нероев, калайчы Матвеев иптәшләр үзләре теләп Сталинград өлкәсендәге МТС ларга эшкә киттеләр.

Шушы көннәрдә Татарстан хезмәт ияләре тарафыннан җыелган әйберләр һәм төзү материаллары төялгән беренче эшелон Сталинград шәһәренә озатылды. Шушы ук эшелонда 125 кешедән торган бер группа инженер-техник работниклар, прораблар һәм төрле квалификациядәге эшчеләр дә киттеләр.

Бу күрсәтелгәннәр әле эшнең башлангычы гына. Сталинградны аякка бастыру буенча халыкның үз инициативасы белән башланып киткән бу патриотик хәрәкәтне тагын да югары күтәрү һәм аңа якыннан җитәкчелек итү урыннардагы партия, комсомол һәм профсоюз оешмаларының сугышчан бурычы.

Даһи полководец иптәш Сталин исемен йөртә торган Сталинград өлкәсен тизлек белән аякка бастырыйк. Аның промышленностен һәм авыл хуҗалыгын элекке төзек хәленә кайтарыйк. Аңа ярдәмебезне тагын да көчәйтик. Төзү материаллары, станоклар, җиһазлар һәм кием-салымнар төялгән эшелоннарны бер-бер артлы герой шәһәргә җибәреп торыйк. Миллион куллар тарафыннан күрсәтелгән безнең ярдәмебезнең уңышлы нәтиҗәләрен азат ителгән туганнарыбыз тизрәк һәм тизрәк күрсеннәр!

Совет Информбюросыннан

31 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

31 нче мартта безнең гаскәрләр Кубаньның түбәнге агымында немецлар оборонасының иң әһәмиятле узелы Анастасиевскаяны алдылар.

Башка фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

* 30 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 5 танкысын, гаскәр һәм йөкләр төялгән 50 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар, бер ягулык складын яндырдылар һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* Көнбатыш фронтта аерым участокларда безнең гаскәрләр җирле әһәмиятле булган сугышлар алып бардылар. Булып үткән яңгырлар һәм карның бик тизлек белән эрүе актив сугыш хәрәкәтләрен кыенлаштыралар. Бер участокта безнең подразделениеләр дошманның сугышчан сакчыларын тар-мар иттеләр һәм алга киттеләр. 100 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 8 пулемет, винтовкалар һәм патроннар кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че берләшмә частьлары өч көн эчендә немецларның бер батальоннан артык пехотасын юк иттеләр, 6 танкысын һәм 4 самоход орудиесен сафтан чыгардылар.

* Төньяк Донецның урта агымы районында безнең подразделениеләр немец пехотасының танклар һәм артиллерия белән көчәйтелгән батальонының атакасын кире кайтардылар. Сугыш кырында үз солдатларының һәм офицерларының 150 үле гәүдәләрен һәм яндырылган ике танкларын калдырып, немецлар элекке позицияләренә чигенделәр.

* Ростов-Доннан көнбатыштарак дошман күпер салырга һәм бер су чиге аркылы кичәргә маташып караган иде. Безнең подразделениеләр артиллерия һәм миномет уты белән гитлерчыларны таркаттылар һәм ашыгыч рәвештә чигенергә мәҗбүр иттеләр.

* Ильмень күленнән көньяктарак немецлар пехотасы безнең позицияләргә атака ясаган иде. Н-че частьның алгы подразделениеләре гитлерчыларның атакасын кире кайтардылар. Дошманның 300 гә якын солдат һәм офицерлары үтерелде.

* Сумы өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары бер тимер юл станциясенә барып кергәннәр һәм 27 гитлерчыны юк иткәннәр. Совет патриотлары 2 паровозны шартлатканнар, 2 пулемет, 22 винтовка, күп кенә патроннар һәм гранаталар кулга төшергәннәр. Винница өлкәсе партизаннарының бер отряды дошман гарнизоннарына берничә тапкыр һөҗүм ясаган һәм 78 немец солдатын һәм офицерын юк иткән. Партизаннар 60 совет гражданын азат иткәннәр. Бу кешеләрне гитлерчылар Германиягә каторга эшенә алып китмәкче булганнар. Шул ук отрядның бер группа партизаннары дошманның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар.

* Немецларның 81 нче пехота полкыннан үзе теләп плен бирелгән солдат Людвиг П. болай диде: «Безнең полк Франциядә Ларошель шәһәрендә иде. 21 нче февральдә без Россиягә киттек. Безнең рухыбыз бик төшенке иде. Безгә Герингның күптән түгел сөйләгән рече бик нык әсәр итте. Бу речендә ул: «Немец солдатының кайда үтерелүе әһәмиятле түгел, бары тик аның үз бурычын үтәве генә әһәмиятле», дигән иде. Бу речь мине бик әсәрләндерде һәм ачуландырды. Мин Герингның сүзләрен болай аңладым: хәзерге вакытта Россиядә булган немец солдатлары барысы да (аларның кайда булулары әһәмиятле түгел — Ленинград фронтындамы, Ильмень күле янындамы яки көньяктамы — барыбер) кайчан булса да үтерелеп бетәчәкләр. Моннан мин, немецлар армиясе оттырганлыгы ачык билгеле булган сугышны дәвам иттерә дигән нәтиҗәгә килдем. Юлда барганда солдатлар көнбатыштан Германиягә булган куркыныч турында үзара бик күп сүзләр сөйләделәр».

* Немец-фашист кабахәтләренең Житомир өлкәсе Рудня-Озерянская авылында эшләгән коточкыч җинаятьләре турында хәбәр алынды. Гитлерчылар авылдан мәктәпкәчә яшьтәге 25 баланы җыеп алганнар һәм хәрби госпитальгә алып киткәннәр. Госпитальдә яралы немец офицерларына күчерү өчен балалардан кан алганнар. Хәлләре һәм каннары беткәнлектән балалар берничә көннән үлгәннәр.

* Бельгиядәге бер паровоз төзелеше заводы эшчеләре белән немец оккупантлар арасында бер ел буена диярлек көрәш бара. Гитлерчылар паровоз эшләп чыгаруны оештырырга маташып караганнар, ләкин эшчеләр аларның барлык чараларын өзгәннәр. Патриотлар җиһазларны ватканнар, технология процессын тупас төстә бозганнар, чималны эштән чыгарганнар һәм башка шундыйлар. Рәхимсез террорга да карамастан, гитлерчылар бер ел буена бу заводтан бер паровоз да ала алмаганнар. Льежда бер группа патриотлар немецларның бер ягулык складына барып кергәннәр һәм төнлә белән резервуарлардагы бөтен бензинны агызып бетергәннәр. Намюр районында Бельгия тимер юлчылары немецларның бер поездын һәлак итүне оештырганнар.

1 нче АПРЕЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

1 нче апрельдә фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 6.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* 31 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән кимендә 70 автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер катерны батырдылар.

* Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары дошман оборонасының алгы кырыена үтеп керделәр һәм немецларның көчле итеп ныгытылган позицияләрен алдылар. Безнең артиллеристлар, пехотаның хәрәкәтләренә булышлык итеп, дошманның 4 миномет һәм 8 артиллерия батареясын юк иттеләр. Икенче бер участокта плен алынган немец солдатлары һәм офицерлары немецларның 267 нче пехота дивизиясенең күп кенә подразделениеләренең соңгы сугышларда бөтен личный составларының 70-80 проценты үтерелгәнлекне һәм яраланганлыкны әйттеләр.

* Белый шәһәреннән көньяктарак сирәк кенә мылтык пулемет атышы булып торды. Н-че часть подразделениеләре, уңышлы маневр ясап, бер ныгытылган пунктта немецлар гарнизонының чолганып алынуы куркынычын тудырдылар. Совет сугышчыларының ударлары астында калган гитлерчылар ашыгыч рәвештә чигенделәр. Сугыш кырында дошманның 150 гә якын үле гәүдәләре калды. Безнең подразделениеләр ныгытылган пунктны алдылар һәм трофейлар кулга төшерделәр.

* Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр оборона эшләре үткәрделәр һәм дошманга каршы атып тордылар. Н-че берләшмә участогында безнең минометчиклар һәм снайперлар уты белән бер ротага якын немец пехотасы юк ителде.

* Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта бер батальон гитлерчылар тар-мар ителде һәм 5 орудие, 19 пулемет, 8 миномет, төрле йөкләр төялгән 13 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* Севск районында дошманның бер батальон пехотасы һәм 7 танкысы безнең позицияләргә атака ясадылар. Баштарак немецлар, безнең сугышчан сакчыларны беразкысрыклап, халык яши торган бер пунктның көнбатыш читенә үтеп керә алганнар иде. Н-че часть сугышчылары, контрудар ясап, дошманны алып ташладылар һәм 200 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. Командиры иптәш Старцев булган частьның снайперлары бер көн эчендә 37 немец солдатын һәм офицерын кырдылар.

* Ленинградка килү юлларында һава сугышында безнең очучылар немецларның 3 самолетын юк иттеләр. Сержант иптәш Дмитриев, зенит пулеметыннан атып, дошманның бер «Мессершмидт — 109» истребителен бәреп төшерде.

* Кировоград өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды халык яши торган бер пунктка барып кергән һәм ремонт мастерскойларын саклаучы 37 гитлерчыны үтергән. Партизаннар немецларның ремонт ясалган автомашиналарын һәм запас частьлар складын юк иткәннәр. Бер группа шартлатучы партизаннар тимер юлга миналар куйганнар. Дошманның шуннан үтеп бара торган бер эшелоны миналарга бәрелеп шартлаган. Бер паровоз, төрле сугыш милекләре төялгән 23 вагон җимерелгән.

* Волхов фронтының бер участогында немецларның 23 нче пехота дивизиясенең 9 нчы полкыннан Иоганн Хейдер һәм Курт Кун дигән солдатлар плен алынды. Алардан Германиядән килгән 48 хат табылды. Бу хатларны пленныйлар кыр почтасыннан үз роталарындагы солдатларга алып кайткан булганнар. Хатлардан күренүенчә, гитлерчылар үткәрә торган тотал мобилизация Германия халкы арасында тирән ризасызлык һәм тревога тудырган.

Х. Экккард Бранденбургтан Вильһельм Хут дигән солдатка болай дип яза: «. . . Мине армиягә алалар. Россия безнең дивизияләрне һәм бик күп марш батальоннарын бер-бер артлы йотып кына тора. Ул әлегә кадәр тылда булганнарны да йотачак. Мондый фор-

(Ахыры 4 нче биттә).

Сталин лауреатларының взносы

Иптәш Сталин исеменә Сталин премиясе лауреатларыннан хатлар килү дәвам итә. Хезмәтләренә югары бәя бирелү белән рухланып, алар иптәш Сталинга рәхмәт сүзләре белән мөрәҗәгать итәләр, үзләренең премияләрен кораллар төзүгә кертәләр һәм ватан өчен тагын да тырышыбрак эшләргә вәгъдә бирәләр.

Язучы Алексей Толстой үзенең «Хождение по мукам» исемле романы өчен бирелгән премияне «Грозный» исемле танк төзүгә бирде.

Лауреатлардан С. Кретов, В. Красильщик, В. Росси, В. Ниловский, Н. Ярменко үзләренең премияләрен Баш Командование фондына керттеләр.

Төсле металлургия наркоматының 7 нче номерлы заводы инженерлары Б. А. Борок, В. К. Гаврилова үзләренең премияләрен Сталин премиясе лауреатлары исемле самолетлар эскадрильясы төзүгә бирделәр.

Иптәш Сталин исеменә Сталин премиясе лауреатлары-академиклар—П. Н. Константиновтан, А. А. Байковтан, Е. А. Чудаковтан, профессор И. Ш. Нейманнан, РСФСР ның халык артисткасы Е. Д. Турчаниновадан һәм язучы Леонид Леоновтан хатлар алынды.

Иптәш Сталин үзенең җавап хатларында лауреатларга Советлар Союзының кораллы көчләре турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен рәхмәт белдерә.

Ярдәмче хуҗалыкларны язгы чәчүгә отлично әзерләргә!

Сталинградны төзекләндерик

БЕРЕНЧЕ ЭШЕЛОННАР

Немец оккупантлары тарафыннан җимерелгән, таланган Сталинградны элекке төзек һәм матур хәленә китерү эшенә бөтен илебез катнаша. Бу изге һәм мактаулы эшкә Татарстан хезмәт ияләре дә кушылдылар һәм Сталинградны төзекләндерү өчен әйберләтә, акчалата ярдәм итүне башлап җибәрделәр.

Шушы көннәрдә Казаннан Сталинградка төзү материаллары һәм башка әйберләр төялгән беренче эшелон озатылды. Бу эшелонда 30 вагон агач материалы, 10 вагон шпал, 4 вагон кирпеч, 2 вагон алебастр һәм башка төзү материаллары, җиһазлар, инструментлар, өс, аяк киемнәре, савыт-сабалар бар. Шушы ук эшелонда 125 кешедән торган бер группа инженерлар, техниклар, прораблар һәм төрле квалификациядәге эшчеләр дә киттеләр. Бу беренче эшелонны җибәрүдә башлыча Татарстан АССР ның Урман промышленносте халык комиссариаты, Казан тимер юл идарәсе, Главснаб, управляющие Ястребелов булган трест һәм башкалар катнашты.

Хәзер икенче эшелонны җибәрүгә әзерлек бара. Бу эшелон да шушы көннәрдә озатылырга тиеш. Вагоннарны тиз төяп, эшелонны вакытында озату җибәреләчәк әйберләрнең алдан әзерләнгән һәм тәртипкә китерелгән булуына, аларга яхшы упаковка ясалуына нык бәйләнгән. Шуның өчен барлык оешмалар һәм комиссияләр Сталинград өчен, бигрәк тә беренче чиратта кирәк булган әйберләрне тизрәк әзерләүгә, аларга яхшы итеп упаковка ясауга, Сталинградка барырга теләүче төзелеш белгечләрен һәм эшчеләр табуга һәм аларны белгечлекләре буенча кирәкле инструментлар белән тәэмин итүгә аеруча нык әһәмият бирергә тиешләр.

Волга, Кама, Вятка һәм Агыйдел буендагы шәһәрләрдән һәм районнардан Сталинград өчен җыелган әйберләр су юлы белән озатылачак. Бу елгаларның пристаньнарына якын районнарда шәһәр һәм район комиссияләре Сталинград өчен әйберләр җыюны ашыктырырга, аларны озату эшен яхшы итеп әзерләргә һәм пристаньнарга ташып куярга тиешләр. Су юлы ачылу белән бу елгаларның пристаньнарыннан йөк төялгән беренче баржалар Сталинградка озатылырга тиеш.

Сталинградны элекке төзек хәленә китерү һәм андагы промышленность предприятиеләрен ходка җибәрү политик һәм хуҗалык ягыннан гаять әһәмиятле урын тота. Без моның белән совет халкының бердәмлеген, эшлеклелеген, авыр сугыш шартларында да зур хуҗалык эшләрен башкара алуга сәләтле булуын тагын бер кат бөтен дөньяга күрсәтә алабыз. Шуның өчен дә урындагы партия, комсомол, совет һәм хуҗалык оешмаларының җитәкчеләре Сталинградка ярдәм итү буенча совет җәмәгатьчелеге тарафыннан күтәрелгән инициативаны тагын да үстерергә һәм аңа конкрет җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр.

Ф. КОВАЛЬСКИЙ,
ТАССР Совнаркомы председателенең урынбасары.

Барлык культуралар чәчелергә тиеш

«Спартак» комбинаты янындагы ярдәмче хуҗалык үткән елгы уңышсыз эшләрен быел кабатламаска тырыша. Хуҗалыкның 200 гектар җиренә чәчәрлек ашлык һәм яшелчә орлыклары хәзердән үк сайланып, билгеләнеп куелды. Ярдәмче хуҗалык каршында быел беренче мәртәбә ремонт мастерское эшли башлады.

Комбинатның парткомы ярдәмче хуҗалыкның бөтен эшләре белән һаман саен кызыксынып, тикшереп тора. Ләкин завком хуҗалыкка берниндн дә ярдәм күрсәтми һәм күрсәтергә дә теләми. Завком председателе ярдәмче хуҗалык каршында хәзергә местком оештыру белән генә чикләнде әле.

Ярдәмче хуҗалыкның бөтен эшләренә турыдан-туры җаваплы кеше — ОРС директоры иптәш Курдин да кайбер җитди мәсьәләләрдә үз бурычын тиешенчә аңлап җиткерми булса кирәк.

—Бик күп төрле культураларны чәчүдән бигрәк, иң элек һәм иң күп итеп бәрәңге утыртырга кирәк, — ди ул.

Мондый бер яклы караш, әлбәттә, дөрес түгел. Сүз юк — бәрәңгене күп итеп утыртырга кирәк. Ләкин, шуның белән бергә, план буенча чәчәргә дип билгеләнгән барлык культуралар да, һичсүзсез, үз вакытында чәчелергә тиешләр.

И. ТУКТАРОВ.

ГАМЬСЕЗЛЕККӘ ЧИК КУЯРГА

Партоешма секретаре иптәш Гольман булган завод ОРС ы соңгы вакытта үзенең эшен бернн кадәр яхшыртты. Ашханә кирәкле продуктлар белән өзлексез тәэмин ителә башлады. Азык продуктларын нормалаштыруга контроль куелды, шуның нәтиҗәсе буларак, ашның сыйфаты күтәрелде. Карточкалар бюросыннан талоннар бирүгә һәм ОРС магазинында аларны урнаштыруга учет булдырылды. Моның аркасында эшчеләр өчен промтоварлар саны шактый артты. Җәмәгать тукlануында һәм сәүдә челтәрендә 'учетның, контрольнең юлга 'салынуы эшчеләрне элеккегә караганда яхшырак тәэмин итүгә мөмкинлек бирде.

Ләкин бу уңышларга карап кына ОРС ның бөтен системасы бүгенге көн сорауларына җавап бирерлек эшли дип әйтеп булмый әле. Аның эшендә һич тә гафу ителмәслек күп кенә җитешсезлекләр дә бар: ашханәгә пар вакытында бирелми, ашаучылар өчен савыт-саба җитешми, кайбер официанткалар бик акрын эшлиләр. Менә шуларның барысы нәтиҗәсендә аш вакытында өстәл янында, кассада чиратлар була һәм эшчеләр еш кына эшкә соңга калалар.

Фонд буенча бирелгән продуктлар, мәсәлән, балык, май һәм шикәр тулысынча готылмыйлар. ОРС магазины икмәк белән сәүдә итүне нормаль төстә алып бармый. Ул чөү хуҗалыгы начар хәлдә.

Кухня һәм ашханә калдыклары базасында дуңгыз симертү пункты оештыру турында күптән сөйләнә инде. Ләкин бу мәсьәләдә конкрет бернәрсә дә эшләнми.

Күптән түгел генә булып үткән профсоюз конференциясе завод ОРС ының эшен ныклап тикшерде һәм аны яхшырту буенча конкрет чаралар билгеләде. Бу чараларны тормышка ашыра башларга, югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләргә чик куярга бик вакыт инде. Беренче чиратта язгы чәчү кампаниясенә әзерләнү бурычы тора. ОРС үзенең ярдәмче хуҗалыгын, эшчеләрнең индивидуаль бакчаларын бәрәңге һәм яшелчә орлыклары белән, авыл хуҗалыгы инвентарьлары белән тәэмин итәргә тиеш.

Ватан сугышы вакытында эшчеләрне тәэмин итү мәсьәләсе зур әһәмияткә ия булып тора. Шуның өчен ОРС эшенең бөтен тармакларына көндәлек ярдәм оештырырга, аларга системалы рәвештә контроль ясап торырга кирәк.

М. ШВАРЦЕР.

КЫЗЫЛАРМЕЕЦ СЕМЬЯЛАРЫНА ЯРДӘМ

ПИОНЕРЛАРНЫҢ ГҮЗӘЛ ЭШЛӘРЕ

Казан шәһәре мәктәпләрендә укучы балалар һәм пионерлар фронтовик семьяларына ярдәм итүдә актив катнашалар. 88 нче номерлы мәктәп пионерлары фронтовик балаларына 126 пар киез итеккә ремонт ясап бирделәр. Молотов районының 101 нче мәктәбендә укучы пионерлар фронтовик семьяларына 25 кубометр утын кистеләр.

Зеленодольскидагы 2 нче номерлы мәктәп укучылары да бу эштә актив катнашалар. Фронтовик хатыны иптәш Цыганенко үзе һәм аның 4 баласы авырый иде. Пионерлар бу семьяга ярдәм оештыру турында киңәштеләр һәм үзара эш бүлештеләр. Алар иптәш Цыганенконың квартирасын җыештырдылар, магазиннан икмәк алып кайттылар, су китерделәр. Балаларга аяк киемнәренә ордерлар алуда ярдәм иттеләр. Пионерлардан Михайлова, Пустовит, Леймович бу эштә аеруча зур активлык күрсәтәләр. 4 нче мәктәп пионерлары (вожатые иптәш Яковлева) фронтовиклар анасы иптәш Недошивинаның утынын кисеп бирүне оештырдылар.

Мондый фактларны пионерлар тормышыннан күпләп китерергә мөмкин. Алар героик сугышчыларның семьяларына булышлык итү өчен һәрвакыт әзер торалар.

Г. ЕРМОЛАЕВА.

ИНДИВИДУАЛЬ ЯШЕЛЧӘ БАКЧАЛАРЫ

Казан шәһәр хезмәт ияләре арасында яшелчә бакчачылыгы белән кызыксынучыларның саны елданел арта. Узган ел шәһәр тирәсендә индивидуаль яшелчә бакчалары өчен 1.281 гектар җир участоклары бирелгән иде. Аларга 85.000 гә якын кеше бәрәңге һәм төрле яшелчәләр утырттылар. Быел индивидуаль яшелчә бакчаларында катнашучыларның саны 100.000 гә җитә. Шәһәрнең Ленин районында индивидуаль яшелчә бакчаларын киңәйтү өчен 380 гектар яңа җир участоклары бирелә. Шуның өстенә шәһәрдә һәм бистәләрдә йорт тирәләрендәге җир участокларыннан киң күләмдә файдалану чаралары күрелә.



Юдино районындагы «Яңа тормыш» колхозы районда беренче булып үзенең парникларын тәртипкә китерде. Рәсемдә: парникка тирес салалар.

К. Тахтеев фотосы.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНДА

Ягулык складларында тәртипсезлек бетерелсен

Хәзерге шартларда тимер юлның төгәл эшләвен тәэмин итүдә утын-ягулык мәсьәләсе бик зур урын тота. Ләкин Юдино бүлегендә моны аңламыйлар булса кирәк. Бу бүлеккә карый торган күп кенә станцияләрнең ягулык складлары начар эшлиләр, локомотивларны үз вакытында ягулык белән тәэмин итүне тоткарлыйлар, түбән сыйфатлы калын һәм юеш утын бирәләр. Мондый зур җитешсезлекнең төп сәбәбе—хәрәкәт бүлеге начальнигы Кротов һәм паровозлар хуҗалыгы бүлеге начальнигы Денисов иптәшләрнең ягулык складлары эшенә һич тә җитәрлек игътибар бирмәүләрендә.

Складларга утын ташыту эше начар оештырылган. Утын ташучы махсус поездлар резерв складларында төялүне көтеп тә, юлда да, төп складларга бушату урыннарында да һәрвакыт простой ясыйлар. Мәсәлән, мондый поездлар Урмар ягулык складында, кагыйдә буларак, нормага караганда икеләч тапкыр вакытларын тик торып әрәмгә үткәрәләр.

Утын складларга аларның ихтыяҗларын исәпкә алмыйча ташыла. Якын урында утын бар икән—аны складка ташый бирәләр. Шуның өстенә, паровоз бүлеге работниклары утынны сыйфатына карап ташытуны һич тә планлаштырмыйлар. Нәтиҗәдә, хәзер Арча һәм Урмар складларында бары тик коры утын гына, ә Шәмәрдән һәм Төрләмә складларында бары тик юеш утын гына өелеп ята. Мондый хәл склад работникларына төрле ягулыкны яхшы итеп аралаштыру мөмкинлеген бирми, ә бу исә поездларның йөреш темпларына, локомотивларның эшләренә начар йогынты ясый.

Аерым машинистлар Шәмәрдән станциясендә 4—5 кубометр гына утын алалар да, Арчага кадәр җитәр әле, дип юлга чыгалар. Нәтиҗәдә, Арча склады паровозлар белән тулган була, склад работниклары аларга утын төяп өлгерә алмыйлар, ә шул ук вакытта Шәмәрдәндәге работниклар эшсез тик торалар. Төрләмә һәм Урмар складларында да шундый ук хәл.

Канаш—Юдино юлында поездларны төгәл үткәреп торуны оештыруда Урмар ягулык складының гаять әһәмиятле урын тота. Әгәр бирелдә локомотивлар утын белән үз вакытында һәм тизлек белән тәэмин ителсәләр, участокта поездлар хәзергегә караганда, бик күп югары темплар белән йөри алырлар иде. Ләкин, кызганычка каршы, бу складның работниклары (начальнигы иптәш Филиппов) үзләренә йөкләтелгән бурычны тиешенчә үтәмиләр. Складта эш бик начар оештырылган. Урмарда склад бик күптән инде эшләп килә. Бу вакыт эчендә анда булган кимчелекләрне ачып салырга, аларны бетерү чараларын күрергә, локомотивларны утын белән тәмин итү эшендә һичбернинди тоткарлык булдырмаска бик мөмкин иде. Ләкин болар берсе дә эшләнмәгән һәм эшләнми. Нәтиҗәдә, складта эш һаман искечә начар килеш калуында дәвам итә.

Юдино паровозлар хуҗалыгы бүлеге начальнигы иптәш Денисов, андагы тәртипсезлекләрне күрергә теләмичә, яки бөтенләй читләтеп үтә, яки бернинди сизелерлек нәтиҗә бирә алмаслык ярым-йорты чаралар күрү белән генә чикләнә. Шунсы характерлы: иптәш Денисов башка складларның эшләренә дә шулай ук бармак аша карый.

Урмар склады начальнигы, үзенең бөтенләй көчсезлеген күрсәтеп, турыдан-туры:

— Ярыш бездә әлегә юк,—ди.— Учет булмагач, нинди ярыш булсын соң...

Чынлыкта да шулай. Паровозларны утын белән тәэмин итү сроклары кебек төп күрсәткеч билгеле булмагач, аерым бригадаларның эшләренә ничек итеп бәя бирәсең? Ә бу складта бөтенләй сәгать юк. Ансыз паровозларга күпме вакыт эчендә утын төялеп бетүен белү мөмкин түгел, әлбәттә.

Күп кенә складларда механик һәм кул балталары (колуннары) хәрәкәтсез яталар, утын төяү эстакадалары әлегә кадәр булдырылмаган. Болар барысы да поездларның йөреш темпларын әкренәйтәләр.

Соңгы вакытларда складларда эшләргә йөзләрчә яңа эшчеләр килде. Алар башлыча, Татарстан, Чувашстан һәм Мари АССР авылларыннан килгән колхозчылар. Бу эшчеләрнең бер өлеше рус телен начар белә. Димәк, бүлек җитәкчеләре һәм беренче чиратта—политбүлек начальнигы иптәш Иванов, ул эшчеләр арасында масса-политик эшләрне үз ана телләрендә оештырып җибәрергә тиеш иде. Бу нәрсә дә эшләнми. Складларда политик - масса эшләр бөтенләй диярлек алып барылмый. Мәсәлән, шул ук Урмар складында бер генә агитатор да юк. Монда, сез, күрсәткеч такталарын да, стена газеталарын да, һичбер нинди плакат һәм лозунгларны да күрмәссез. Бу инде, локомотивларны утын белән тәэмин итү кебек мөһим эш алып баручы һәм төрле милләтләрдән булган күп йөзләрчә эшчеләр турында политбүлек работниклары бөтенләй онытканнар дигән сүз.

Ягулык складларында эшне бу килеш һич тә калдырырга ярамый. Казан тимер юлы идарәсе һәм политбүлеге ашыгыч рәвештә практик чаралар күрергә тиеш.

Н. ГУСЕВ.

ОРЛЫКЧЫЛЫКНЫ ЯХШЫРТУ БУЕНЧА КОЛХОЗЛАРНЫҢ ЭШЕ ТУРЫНДА

Иген уңышын күтәрү өчен һәрбер колхозда орлыкчылыкны яхшыртуның зур әһәмияте булганлыктан, Союз Наркомземы бу турыда махсус приказ чыгарды. Приказда, тикшерү нәтиҗәсендә, җир органнарының һәм күп кенә колхозларның орлыклык участокларында үстерелгән яхшы орлыклар белән колхозларны тәэмин итү эшен бик начар алып барулары күрсәтелә.

Колхозларның бер өлешендә орлыклык участоклар аерып кую буенча хөкүмәт карарлары белән билгеләнгән тәртип, шулай ук орлыклык участокларны бик яхшы итеп эшкәртү, яхшы орлыклар чәчү, вакытында урып-җыю, җыелган уңышны чәчү кирәкләре өчен әзерләп кую таләпләре үтәлми. Орлыклык участокларда чәчү еш кына ашланмаган, тунга сөрелмәгән җирләргә яки пар җирләре вакытында сөрелмәгән һәм эшкәртелмәгән хәлдә үткәрелә. Орлыклык участоклар звеноларга беркетелми, бу хәл аларны тәрбияләүдә иясезлек булуга китерә. Орлыкчылык эшенә дөрес караш булмау аркасында мондый колхозлар түбән уңыш алалар, бик күп зыян күрәләр һәм колхозчыларга хезмәт көннәренә аз түлиләр.

СССР Наркомземы барлык җир органнарын, 1943 нче елны һәрбер колхозның үзен яхшы орлыклар белән тулысынча тәэмин итүенә ирешергә мәҗбүр итте. Культуралы итеп куелган орлыкчылык эше һәм яхшы орлыклар һәрбер колхозның мактанычы булырга тиеш.

Һәрбер колхозда, кыр эшләре башланганчыга кадәр, хөкүмәтнең «1942 нче елны игеннәрне урып-җыю һәм авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү турында» гы карары белән билгеләнгән күләмнәрдә, тиешле культураның чәчү мәйданына карата мәгълүм процентта, орлыклык участоклар билгеләнергә һәм алар натурада башка участоклардан чикләнеп куелырга тиеш.

Орлыклык участокларга чүп үләннәрдән чистартылган иң яхшы җирләр билгеләнергә тиеш, аларга чәчү җирне яхшы итеп эшкәрткәннән соң, иң яхшы сыйфатлы, сайлап алынган сортлы орлыклар белән үткәрелергә тиеш.

Барлык колхозларда аеруча тәҗрибәле колхозчылардан орлыкчылык звенолары аерып куярга, бу звеноларны җанлы тарту көче һәм авыл хуҗалыгы инвентаре белән тәэмин итәргә кирәк. Колхозларга, звенолар эчендә техник, майлы һәм башка төрле сызма культуралар чәчүлекләрен аерым колхозчыларга беркетергә киңәш бирелә.

Җир органнары һәрбер колхозда правление членнарыннан берсен орлыклык участокларга мөдирлек итү өчен билгеләп куюны тәэмин итәргә, ә агрономнары булган колхозларда бу эшне аларга йөкләргә тиешләр.

Колхозларга, орлыклык участокларга мөдирлек иткән өчен, алынган нәтиҗәләргә карап, билгеләнгән тәртипкә туры китереп, өстәмә түләү бирергә киңәш бирелә.

Союз Наркомземы, орлыклык участоклардан югары уңыш алу өчен, җир органнарын, түбәндә күрсәтелгән агротехника чараларын үткәрүне тәэмин итәргә мәҗбүр итте: Кыр эшләре башлануның беренче ике-өч көне эчендә тунга сөрелгән участокларда тырмалау үткәрергә, шулай ук иртә чәчелә торган сабан культуралары өчен чәчү алдыннан җирне культивацияләргә һәм тырмаларга; әгәр дә орлыклык участоклар тунга сөрелмәгән булса, ул чагында яздан сөрүне язгы кыр эшләренең беренче көннәрендә нормаль тирәнлеккә үткәрергә һәм шул ук вакытта тырмаларга; соң чәчелә торган сабан культураларына билгеләнгән участокларны чәчүгә кадәр кимендә ике тапкыр культивацияләргә һәм шул ук вакытта тырмаларга; һәрбер колхозда җирле ашламалар җыюны алдан ук оештырырга һәм аларны беренче чиратта орлыклык участокларга кертергә; орлыклык участокларда чәчүлекләрне бөтен үсү вакыты буена чүп үләннәре басмасын өчен, кирәк кадәр санда утау үткәрергә, ә сызма культуралар җирләрендә, шуның өстенә, рәт араларын кирәк кадәр санда эшкәртергә.

МТС директорлары беренче чиратта орлыклык участокларны эшкәртүне, аларны тәрбияләүне һәм алардагы игеннәрне урып-җыюны күздә тотарга тиешләр. Орлыклык участоклардагы уңышны урып-җыеп алу һәрбер культура өчен иң яхшы дип саналган агротехник срокларда үткәрелергә һәм алынган уңыш кичекмәстән сугылырга тиеш.

Сукканнан соң бөтен орлыкны чистартырга, сортларга аерырга, актлар белән рәсмиләштерергә һәм расписка белән складка тапшырырга кирәк. Орлыклык участоклардан алынган орлык башка ашлыклардан аерым сакланырга тиеш.

Колхозларда орлыклык участоклар буенча эшкә җитәкчелек итү район җир бүлекләренең баш агрономнарына йөкләнә. Аларга колхозларда орлыкчылык эшенә җитәкчелек итүгә, контроль алып баруга һәм бу эшне оештыруга район җир бүлегендә, МТС та, контроль - орлыкчылык лабораторияләрендә, сорт сынау участокларында һәм СССР Наркомземы системасының башка хуҗалыкларында эшләүче агрономнарны тарту хокукы бирелә. Колхозларда орлыкчылык эшен оештыруда үзләрен аеруча күрсәтә алган, орлыклык участоклардан югары уңыш алуга ирешкән агрономнар, кызыксындыру һәм бүләкләү өчен, СССР Наркомземына тәкъдим ителәләр.

Участокларны аерып бирүдә һәм орлыкларны чәчүгә әзерләүдә колхозларга булышлык итү өчен җир органнарының, МТС ларның, фәнни-тикшеренү учреждениеләренең һәм уку йортларының агрономнары җибәрелә.

ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БАШЛАНДЫ

Язгы чәчүгә әзерлектә булган кечкенә генә кимчелекнең дә соңыннан, кызу эш өстендә зур тоткарлыклар тудырачагын хәтердән чыгармыйк. Тикшерү вакытында ачылган барлык кимчелекләрне шунда ук бетерик!

Колхозларның орлык фондына

Совет патриотлары взносы

111. ШАРАПОВ Ф.—Алексеевский районы, «Кызыл Октябрь» колхозы члены, 60 яшьлек карт, фронтовик атасы—62,5 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге бирде.

112. МУЛЮКОВ С.—Кукмара районы, «Кустарь» колхозы члены, 81 яшьлек карт, ике улы фронтта—30 пот ашлык һәм 20 пот бәрәңге бирде.

113. МЕРКУЛОВ П.—Алексеевский МТС ы машинисты—31 пот ашлык бирде.

114. ҖИҺАНГИРОВ С.—Шөгер районы, «Спартак» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

115. ӘХМЕТОВ В.—Тымытык районы, «Каен күл» колхозы члены—43,5 пот ашлык бирде.

116. НАСИРОВ—Ютазы районы, «Игенче № 1» колхозы члены—42 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде.

117. ЕРМАКОВ Н.—Аксубай районы, «Комбайн» колхозы члены—12 пот ашлык һәм 9 пот бәрәңге бирде

БӨТЕН НӘРСӘ ӘЗЕР

«Урай» колхозы членнары һәр эшне вакытында, җиренә җиткереп эшләргә яраталар.

Менә язгы чәчү якынлаша. Биредә кыр эшләренә кирәкле бөтен нәрсә күптән әзер. Чәчү машиналары, сабаннар, тырмалар, культиваторлар яхшы итеп ремонтланган. Сбруйлар да артыгы белән әзерләнгән. 60 баш эш аты өчен 80 камыт, 80 постромка бар. Язгы кыр эшләре вакытында кырда җәмәгать туклануы оештырылачак. Моның өчен кирәкле ярма, он кебек продуктлар бүлеп куелган.

Колхоз быел 460 гектар мәйданда язгы чәчү үткәрәчәк. Моның өчен кирәкле чәчү орлыгы кат-кат чистартылып, яхшы кондициягә китерелгән. Бодайның тишелеше—95, солының—97, борчакның — 99 процент. Чәчү орлыгының саклануы әледән-әле тикшерелеп торыла. Колхоз үзеннән арткан 100 центнер солы, 20 центнер бодай, 10 центнер тары һәм 3 центнер көнбагыш орлыгын башка колхозларга бурычка биреп тора. Шулай ук колхозчылар үз хуҗалыкларындагы ашлыктан башка колхозларга 40 гектарга җитәрлек чәчү орлыгы бурычка бирәләр.

Колхозчылар язгы кыр эшләрен зур дәрт белән көтәләр. Алар үзләренең кайда, нәрсә эшләячәкләрен яхшы беләләр.

Язгы кыр эшләренә катнашачак барлык колхозчылар агротехника укуларына йөриләр. Алар туфракның үзенчәлекләре, ашлама кертү һәм сөрү, чәчү, тырмалау техникасы турында махсус дәресләр үтәләр.

Кыскасы, «Урай» колхозы язгы чәчүгә Заинский районының башка колхозларына үрнәк булырлык төстә әзерләнгән һәм аны шулай ук үрнәк булырлык итеп үткәрүенә ышаныч зур.

А. ВӘЛИЕВ.

Смотр башланды

ЮГАРЫ ОСЛАН, 1 апрель. **(Телефон буенча).** Язгы чәчүгә әзерлеккә смотр башлану уңае белән район партия һәм совет активы җыелышы булды. Биредә алар смотрны оештыру тәртипләре һәм ачылган кимчелекләрне бетерү чаралары белән таныштылар.

Шул ук көнне районнан 60 кеше колхозларга китте. Барлык колхозларда тикшерү комиссияләре төзелде. Тикшерү нәтиҗәләрен беркетү өчен акт формалары җибәрелде. Бүген күп кенә колхозларда смотр башланды.

* * *

СТОЛБИЩЕ, 1 апрель. **(Телефон буенча).** «Спартак» колхозының язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү буенча оештырылган комиссия күп кенә кимчелекләрне ачты. Колхозда чәчүлек орлык һаман да җитәрлек тупланмаган. Моның өчен колхозның үзендәге һәм колхозчы хуҗалыкларындагы запаслардан файдалану тиешенчә оештырылмаган. Атларның торышы да начар. Ябык атлар әле дә аерым тәрбиягә куелмаган.

Хәзер комиссия авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтның сыйфатын тикшерә башлады.

Тикшерү вакытында ачылган кимчелекләрне бетерү буенча шунда ук ныклы чаралар билгеләнә.

* * *

ЧЕПЬЯ, 1 апрель. **(Телефон буенча).** Бүген язгы чәчүгә әзерлекне тикшерү смотрының беренче көне. Бүген колхозларда тикшерү комиссияләре төзелде һәм җыелышлар үткәрелде. Аларда колхозчылар тикшерүнең бурычлары һәм аны үткәрү тәртипләре белән таныштырылды.

Аерым колхозларда тикшерү дә бүген үк башланды. Мәсәлән, 5 колхозда авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьларга ремонтның сыйфаты тикшерелде. Комиссияләр бу колхозларда агротехника чараларын үткәрүнең сыйфаты белән таныша башладылар.

ШӨГЕРЛЕЛӘР ОНЫТКАН БЕР ЭШ ТУРЫНДА

Шөгер районында теге яки бу хуҗалык кампаниясен уздырганда тарту көчләре җитмәүдән зарланырга яратучылар ансат табыла. Узган елгы язгы, көзге чәчүнең агротехник срокларын өзелүгә дә, тунга сөрү планының үтәлмәвенә дә, дәүләткә ашлык тапшыру эшен озакка сузуга да беренче чиратта шушы сылтауны ишетергә туры килә. Кыш үтеп бара, районда басуга тирес чыгаруның кышкы планы бары 68 процентка гына үтәлгән. Күп кенә колхоз җитәкчеләре моңа да сылтау итеп тарту көчләренең җитмәвен күрсәтәләр.

Сугыш обстановкасында тарту көчләренең бер өлеше кимүе гаҗәп түгел, ләкин бит ул кимүне урындагы шартлардан чыгып, мөгезле эре терлекләрне җигәргә өйрәтү исәбенә капларга бик мөмкин. Ә бу мәсьәлә буенча күпчелек колхозларда конкрет бернәрсә дә эшләнми.

«Победа № 2» колхозы барлык эшләр буенча артта бара. Биредә үткән елгы бөтен җәйге кыр эшләренең яхшы сроклары өзелде. Басуга тирес чыгару буенча былелгы план да өзелү куркынычы астында. 3.600 тонна урынына бары 1.100 тонна тирес чыгарылган. Колхоз председателе Жаков боларның барысына да зур сылтау итеп ат көченә нагрузканың күп булуын күрсәтергә әзер тора. Ләкин аның мөгезле эре терлекләрне җигәргә өйрәтүне оештыру буенча конкрет бернәрсә дә эшләгәне юк. Район җир бүлеге планы буенча биредә 12 баш мөгезле эре терлек җигәргә өйрәтелергә тиеш. Ләкин алар хәзергә кадәр сайлап та алынмаган, бригадаларга да беркетелмәгән. Бер башка да сбруй әзерләнмәгән. Өйрәтүчеләр билгеләнмәгән.

Маркс исемендәге колхозда кыр эшләренә 18 баш мөгезле эре терлек җигәргә өйрәтелергә тиеш. Колхоз председателе Камалиев исә планны бригадаларга бүлеп бирү белән тынычланган. Монда әле һаман «сбруйлар ясарга җыенып йөрү» дән уза алмыйлар. Хуҗалыклардагы сыерларны өйрәтү турында колхозчылар белән сөйләшү, аларга СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарында күрсәтелгән чаралар турында аңлату оештырылмаган.

Куйбышев исемендәге, «Шушма», «Ярыш», «Үзәк» колхозларында да бу эш буенча карар өстенә карар чыгарып бушка сөйләнеп йөрүдән башка күзгә күренерлек бернәрсә дә эшләгәннәре юк.

Мөгезле эре терлекләрне җигәргә өйрәтү эшенең шундый хәлдә булуы очраклы түгел. Район оешмалары, аерым алганда район җир бүлеге, бу эшкә җитәкчелек итми. Район җир бүлегенең өлкән зоотехнигы иптәш Ижбулдин, бөтен гаепне колхоз председательләренә аударып, үзен бөтенесен дә эшләгән кеше итеп хис итә:

— Колхоз председательләре оештырырга тиеләмиләр, теләсәң нишлә,—ди ул.

Чынбарлык исә эшнең анда гына түгел икәнен ачык күрсәтә. Район җир бүлеге колхозларга 500 баш мөгезле эре терлекләрне җитәргә өйрәтергә план төшерү белән чикләнгән. Аның күпмесе өйрәтелгән, күпме сбруй әзерләнгән — бу турыда район җир бүлегендә берәү дә белми. Зооветеринария работниклары аз продуктлы сыерларны сайлап алуда, транспорт сбруйлары әзерләүдә колхозларга практик булышлык итмиләр. Алар күбрәк вакытларын кабинетта үткәрәләр. Кайбер колхозларда хәзергә кадәр сыерларны нинди камыт белән җигәргә икәнен белмиләр. Район җир бүлегенең зоотехнигы иптәш Ижбулдин сводкасы буенча узган ел районда 64 баш мөгезле терлек җигәргә өйрәтелгән булган. Ләкин моңа ышануы кыен. Иптәш Ижбулдин, хәзер аларның 48 е бар, дип раслый. Район җир бүлеге мөдире иптәш Бикжуловның әйтүенә караганда, алар 45 кенә. Фактта хәзер җигүле мөгезле терлекләр саны бармак белән генә санарлык.

Болар барысы да Шөгер районында бу әһәмиятле эшкә бәя бирмәүчелекне ачык күрсәтәләр. Тиздән сабан өсте килеп җитә. Кыр эшләре вакытында быел тагын тарту көчләренә сылтанучылар табылмасмы әле? Карап карыйк.

М. ХӘМИДУЛЛИН,
«Кызыл Татарстан» ның үз хәбәрчесе.

ИЛ ҺӘМ ФРОНТ ИНТЕРЕСЛАРЫ ӨЧЕН

Безнең «Берлек» колхозы Бөгелмә районында кечкенә колхозларның берсе. Ул 29 хуҗалыктан тора. Колхоз кечкенә булса да ул, фронтка зур ярдәм итә. Изге ватан сугышы чорында колхоз үзенең эшен хәрби ладка үзгәртеп корды. Колхозчылар илгә һәм фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын тагын да күбрәк бирү өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр.

Колхозда үткән елны барлык дәүләт йөкләмәләре срогыннан элек үтәлде. Колхозчылар танклар колоннасы төзүгә 101.000 сум, самолетлар эскадрильясы төзүгә 23.423 сум акча җыеп тапшырдылар. Аннары Кызыл Армиягә ярдәм фондына 15.000 сум акча, 1.053 пот ашлык, 78 килограмм бал, 156 килограмм ит һәм башка продуктлар, күп кенә җылы киемнәр бүләк иттеләр.

Быел язгы чәчүне уңышлы үткәреп һәм югары уңыш алуга ирешеп илгә, фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын тагын да күбрәк бирү өчен колхозчылар фронттагы кебек эшлиләр. Язгы чәчү өчен кирәкле барлык машиналар, авыл хуҗалыгы кораллары тулысынча әзер, чәчү орлыгы җитәрлек һәм ул яхшы кондициягә китерелгән. Колхозчылар чәчү орлыгы җитмәгән колхозларга үзләреннән арткан ашлыкларын бурычка биреп торалар.

Г. МИҢНУЛЛИН.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

1 нче АПРЕЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

мада тоталь сугышны бик аз вакыт кына алып барырга мөмкин. Безнең хуҗалык тиздән тәмам җимереләчәк». Фриц Штарбек үзенең туганына болай дип яза: «. . . Озакламый Карлны да зенитчик итеп алачаклар. Алтынчы һәм җиденче класс укучылары дүшәмбе көнгә чакырылдылар. Алар солдатлар кебек тотылалар һәм форма киеп йөриләр. Син уйлап кына кара инде, безнең тормышыбызны балаларга ышанып тапшыралар. Алар безне англичаннарның һава һөҗүмнәреннән сакларга тиешләр. Тәҗрибәле зенитчикларны Россиягә җибәрәләр. Анда алар пехотачы булып сугышачаклар». Торн шәһәреннән Герберг Ганский Карл Ланге дигән солдатка болай дип яза: «Монда буталыш хөкем сөрә. Бөтен халыкны армиягә чакыралар. Хәзер инде гариплэр дә яраклыга әйләнделәр».

Солдат Альфред Оттога аның Берлиндагы кардәшләре болай дип язалар: «Без сугыштан тәмам туйдык инде. Искиткеч җиңүләр турында шундый ашыгыч хәбәрләр килгәннән соң һәркем, сугыш тиздән бетәр дип уйлаган иде. Аның урынына безгә үзебезне тоталь мобилизация белән котларга мөмкин. Юк, булырга мөмкин булган иң зур куркынычлар белән булса да тизрәк бетсен генә иде инде. Чиге булмаган дәһшәтләргә караганда дәһшәтле чик яхшырак».

—◆—

Совет күчмә кинолары немецлар тылында

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Экранда «Райком секретаре» кинофильмы күрсәтелә. Тамашачылар вакыйгаларны тирән игътибар белән күзәтәләр. «Тамаша залындагы обстановка экранда күренгәннәргә бик охшый. Картина партизаннар лагерендагы землянкалардан берсендә бара.

Монда совет ватанын «Зур җир» дип атыйлар. Шул зур җирдән еракта яшәүче Беллоруссия партизаннары үз ватаннарының тормышыннан читтә яшәмиләр. Алар радио тапшыруларын тыңлап һәм белорус һәм рус телендә чыккан газеталарны һәм әдәбиятны укып кына калмыйлар, бәлки кинофильмнарны да регуляр рәвештә карап баралар.

Монда киноустановканы китерүче киномеханик һәм аның иптәшләре өчен зур куркынычлар белән бәйләнгән. Шуңлыктан аларның килүе лагерьда зур бәйрәм төсен ала. Партизаннар һәм оккупацияләнгән күп кенә авыллардагы белоруслар быел гына да «Чапаев», «Ленин 1918 нче елда», «Максимның яшьлеге», «Максимның кайтуы», «Москва янында немецларны тар-мар итү», «Райком секретаре» картиналарын һәм союзкинохрониканың унлап журналын карадылар.

—◆—

Ровнода гитлерчыларның коточкыч ерткычлыгы

СТОКҺОЛЬМ, 30 март. (ТАСС). Гитлерчыларның «Дейче цейтунг ин Украине» газетасының хәбәр итүенә караганда, Ровно шәһәрендәге төрмәгә ябылган берничә совет гражданы качарга уйлаган. Ләкин аларны тоткарлаганнар. «Куркынычсызлык полициясе начальнигының боерыгы буенча, — дип яза газета,—үч алу максатлары белән шул ук көнне бу төрмәдәге барлык тоткыннар үтерелделәр».

Композитор В. П. Соловьев-Седойга «Вечер на рейде», «Играй, мой баян», «Песня мщения» исемле әсәрләре өчен Сталин премиясе бирелде. Рәсемдә: Сталин премиясе лауреаты композитор Соловьев-Седой.

ТАСС Фотохроникасы.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

Сталин премиясе лауреатларының иҗатларын күрсәтү атналыгы

Сәнгать работникларының үзәк йортында 1 нче апрельдән башлап, Сталин премиясе лауреатларының иҗатларын күрсәтү атналыгы башлана. Беренче кичәнең программасы композиторлардан С. Прокофьев, М. Коваль, А. Хачатурян, В. Шибалин, Б. Асафьев, В. Соловьев-Седой, Н. Иванов-Радкевичларның әсәрләренә багышлана.

Чираттагы кичә 2 нче апрельдә була һәм ул язучылардан, шагыйрьләрдән, һәм драматурглардан 10 кешенең әсәрләренә багышлана. Әсәрләрне башкаруда авторлар, Москва театрларының, Филармониянең һәм радиокомитетның артистлары катнашачак. 3 нче апрельдә Ногинский драма театрының спектакле булачак. Бу театр Москвада беренче итеп Сталин премиясе лауреаты Л. Леоновның «Нашествие» исемле пьесасын күрсәтәчәк. 7 нче апрельдә Сталин премиясе лауреатларының йомгаклау кичәсе үткәрелә. (ТАСС).

БОЛГАРИЯ ПАРЛАМЕНТЫНЫҢ ШАУ-ШУЛЫ УТЫРЫШЫ

ИСТАМБУЛ, 30 март. (ТАСС). Софиядән алынган мәгълүматларга караганда, күптән түгел Болгария парламентының 42 депутаты, парламент председателе урынбасары Пешев белән берлектә, Франциядән һәм Македониядән барлык еврейләрне властьларның күчерүе турындагы мәсьәләне кичекмәстән карауны таләп итеп, хөкүмәткә мөрәҗәгать иткән. Бу провинцияләрдәге еврейләрне көчләп Польшага озаталар, анда аларны авыр эшләрдә файдаланалар һәм кырылып бетүгә, үлеп бетүгә дучар итәләр.

Депутатларның хаты хөкүмәт утырышында 108 депутат катнашы белән тикшерелгән, шул ук вакытта Филов хөкүмәткә ышаныч белдерү мәсьәләсен дә куйган. 38 депутат хөкүмәткә ышаныч белдерүгә каршы тавыш биргән һәм 10 депутат бер якка да тавыш бирмәгән. Шуннан соң Пешевка отставкага чыгарга тәкъдим иткәннәр, ләкин ул моны үтәүдән баш тарткан. Шуның артыннан ук парламент утырышы булган, анда депутат Атанас Попов, хөкүмәтнең күрсәтүе буенча, Пешевны парламент председателе урынбасары постыннан алу турында тәкъдим керткән. Бу хәл депутатлар арасында ризасызлык тудырган, алар Пешевка сүз бирүне таләп иткәннәр, ләкин председательлек итүче Калфов Пешевка сүз бирүдән баш тарткан һәм, залдагы шау-шудан файдаланып, Поповның тәкъдиме кабул ителде, дип белдергән. Аннары чыгып сөйләгән оппозицион депутатлардан Стайнов, Кожухаров, Мушанов һәм Доржанский хөкүмәтнең политикасын кискен рәвештә тәнкыйтьләгәннәр. Депутат Мушанов, хәзерге Болгария хөкүмәтенең һәм парламентының политикасы Болгария тарихында кара тап булып тора, дип белдергән. Калфов, куркытулар белән Мушановның речен бүлдерергә маташкан, ләкин Мушанов үзенең чыгышын дәвам иткән һәм белдерүен кабатлаган.

БРЮССЕЛЬДӘ ЧУАЛЫШЛАР

ЛОНДОН, 30 март. (ТАСС). АФИ агентлыгының тапшыруына караганда, шушы көннәрдә Брюссельдә көчле чуалышлар булган. Шәһәрдә 3 немец офицеры һәм 2 солдат үтерелгән. Германиянең оккупация властьлары Брюссельгә провинциядән гаскәрләр китергәннәр һәм Бельгиянең башкаласын чолгап алганнар. Урам чатларына һәм тыкрыкларына пулеметлар куелган. Немецлар кешеләрне йортлардан куып чыгарганнар һәм пулеметлар белән куркытып төн буе урамда торырга мәҗбүр иткәннәр. Коралланган немец солдатлары берничә мең кешене җентекләп тентегәннәр. 600 ләп кеше кулга алынган.

Хәбәр итүләрнә караганда, шулай ук бик күп немец солдатларын да тентегәннәр, чөнки Брюссельдәге немец гарнизонының күп кенә частьларын СССР га каршы фронтка җибәрү турында сүзләр йөрү уңае белән, солдатлар арасында да тынычсызлык сизелгән.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 31 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә белдерелүенчә, Англиянең 8 нче армиясе үзенең төньякка таба алга баруын дәвам иттереп, кичә иртә белән Метуйа һәм Удерф пунктларын алган. Дошман ашыгыч рәвештә әзерләнгән оборона позицияләрендә ныгып калырга маташа. Гафса секторында союзниклар гаскәрләре, миналанган кырларны үтеп, алга киткәннәр, әтөньякта Седженанены алганнар.

Алжир радиосының хәбәр итүенә караганда, Уссельтиа һәм Фай-Да районнарында хәзер бик каты сугышлар бара. Немец гаскәрләре Сфакска таба чигенәләр.

Англиянең хәрби диңгез флоты Габестан төньякка таба яр буйлап чигенүче немец колонналарын өзлексез рәвештә бомбага тота.

Америка гаскәрләре америкалыларны 8 нче армиядән аерып тора торган районны дошман гаскәрләренең калдыкларыннан чистарту өчен кичә Эль-Гаттардан алга таба хәрәкәт итә башлаганнар.

АНГЛИЯ БОМБАРДИРОВЩИКЛАРЫНЫҢ БЕРЛИНГА һӘМ РУРГА һӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 30 март. (ТАСС). Англия авиация министрлыгының белдерүендә әйтелүенчә, 30 нчы мартка каршы төндә Берлин яңадан бик нык бомбага тотылган. Бу операциядә катнашкан бомбардировщикларның 21 е үз базаларына кайтмаган.

Самолетларның башка берләшмәләре Рурның Бохумдагы һәм башка урыннардагы күп кенә объектларына һөҗүм иткәннәр. Рурга ясалган һөҗүмнән 12 бомбардировщик кайтмаган.

КОЛХОЗЛАРДА ЯСЛЕ һӘМ МӘЙДАНЧЫКЛАР

Татарстан колхозларында кыр эшләре вакытында балалар өчен сезонлы ясләләр һәм мәйданчыклар оештыруга әзерлек бара. Үткән ел ачылган 3.172 ясләдә 139 меңнән артык бала тәрбияләнгән иде. Быелгы план буенча 147 мең койкалы 3.315 ясле оештырылырга тиеш. Шулардан 400 ясле язгы чәчү вакытында ачыла. Болардан тыш колхозлардагы даими ясләләрдә 3.325 бала тәрбияләнә.

Ясләләргә мөдирләр әзерләү өчен барлык районнарда курслар оештырылды.

Татарстан сәламәтлек саклау халык комиссариатына алынган мәгълүматларга караганда, күп кенә районнарда сезонлы ясләләр ачуга әзерлек башланган. Тымытык районы колхозларында 30 ясле ачыла. Алар бөтенесе дә биналар белән тәэмин ителгән. Колхозлар ясләләр өчен азык фондлары билгеләгәннәр. Ясләләргә мөдирләр әзерләү өчен өч урында курслар эшләп килә. Чепья, Буа, Кызыл юл, Акташ, Тәтеш, Кукмара, Кайбыч районнарындагы колхозларда да ясләләрне бина һәм азык фондлары белән тәэмин иткәннәр. Ясләләргә медицина работниклары беркетелгән. Ләкин күп кенә ясләләр өчен җиһаз һәм савыт-саба әйберләре җитәрлек түгел. Хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетлары җирле чималдан савыт-саба, җиһазлар һәм башка әйберләр җитештерү өчен ашыгыч чаралар күрергә, кыр эшләре вакытында барлык ясләләрнең һәм мәйданчыкларның нормаль эшләүләрен тәэмин итәргә тиешләр.

— Татарстан Мәгариф халык комиссариаты планы буенча быел колхозларда 120 мең бала өчен 2.545 мәйданчык оештырылырга тиеш. Узган ел 2.475 мәйданчыкта 113 меңгә якын бала тәрбияләнгән.

Күп кенә колхозларда мәйданчыклар оештыруга әзерлек бара. Бу эштә укытучылар зур активлык күрсәтәләр. Югары Ослан районында 250 бала өчен 8, Чепья районында 425 бала өчен 17 мәйданчык ачыла.

Казанның балалар бакчалары шәһәргә якын булган кайбер районнарның колхозларын шефлыкка алдылар. Бауман районы бакчалары Биектау районына, Сталин һәм Дзержинский районнары—Арча районына, Киров һәм Ленин районнары—Юдино районына, Молотов һәм Свердлов районнары бакчалары Югары Ослан районына шефлык итәләр. Бу районнардагы колхозларда мәйданчыклар оештыруга булышлык күрсәтү өчен балалар бакчаларыннан вәкилләр җибәрелде. Шәһәрдәге бакчалар колхоз мәйданчыклары өчен үз көчләре белән уенчыклар әзерлиләр.

Кайбер районнарда, шул исәптән Столбище районында ясләләр һәм мәйданчыклар оештыруга әзерлек бик начар бара. Ясләләр һәм мәйданчыклар бина, азык һәм башка әйберләр белән тәэмин ителмәгәннәр.

Балалары булган барлык колхозчы хатыннар авыл хуҗалыгы эшләрендә катнаша алсыннар өчен, сезонлы ясле һәм мәйданчыклар ачуга әзерлекне кичекмәстән тәгәлләргә кирәк.

ЯҢА ПОЭМА

Совет язучылары союзында, Зоя Космодемьянская турында язылган яңа поэманы уку-тикшерү үткәрелде. Поэманың авторы—талантлы яшь шагыйрь фронтовик Нурый Арсланов.

Данлыклы ватан кызы, Советлар Союзы Герое Зоя Космодемьянскаяның гүзәл һәм героик образы әсәрдә яхшы тупланган һәм җыйнак төстә бирелгән. Автор үзенең бу поэмасын югары художестволы итеп, зур дулкынлану белән язган, һәм ул укучының йөрәгенә тирән барып керә һәм аны да көчле дулкынландыра.

Поэма турында фикер алышуларда катнашкан К. Нәҗми, Х. Госман, С. Фәйзуллин, Л. Җәләй, Г. Халит, К. Газый, Х. Хәйри иптәшләр, яхшы хисләргә, тирән фәлсәфәгә һәм матур буяуларга бай булган бу әсәрнең татар совет поэзиясендә зур уңыш булуы турында сөйләп, аны тизрәк бастырып чыгару һәм киң массага тарату кирәклеген әйттеләр

—◇—

ЧИСТАЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШ АЙЛЫГЫ

Зеленодольск шәһәренең хезмәт ияләре 21 нче марттан башлап, шәһәрдә чисталык өчен көрәш айлыгы игълан иттеләр. Бу инициативага 3 нче номерлы фанера заводы эшчеләре һәм хезмәткәрләре дә бердәм кушылдылар. Айлыкның беренче көнендә эшчеләр поселогының урамнарын, йорт тирәләрен төрле пычраклардан, ташландыклардан чистарту буенча өмә оештырылды. Бу өмәгә йөзләрчә эшчеләр, хезмәткәрләр һәм йорт хуҗалары катнашты.

Айлыкка башка предприятиеләрнең эшчеләре һәм хезмәткәрләре дә кушылдылар. Шәһәрне чистарту буенча күп кенә чаралар үткәрелә.

—◇—

ТЫРЫШ АУЧЫ

Николай иптәш Кузнецовка хәзер 67 яшь. Ул Кәләй авылында иң оста аучы. Әлмәт районының башка авылларында да аны яхшы беләләр.

Иптәш Кузнецов 1943 нче елга кергәч кенә дә 9 төлке, 2 бүре, 2 сосар һәм 50 куян тотты инде.

Ул барлык җәнлек тиреләрен райпотребсоюзның хәзерләүләр конторасына тапшырды.

—◆—

БЕЛДЕРҮ

3 нче апрельдә, 19 сәгатьтә, Партия мәгарифе йортында лекция була. Тема: «Сталинград янында немецларны тар-мар итүнең хәрби-политик әһәмияте. Лектор—Диктович.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

ТЕАТРЛАРДА һӘМ КИНОЛАРДА

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген—«ИЛДАР».

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 6 нчы апрельдә—«ХУҖА НАСРЕТДИН».

Зур драма театры. Бүген—«РУС КЕШЕЛӘРЕ».

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген—Менжинский исемендәге клубта—«БЕР СТАКАН СУ».

«Электро» — көндез «ПАРТИЗАННАР УКРАИН ДАЛАЛАРЫНДА», кич «ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР». **«Унион»** — «ПАРТИЗАННАР УКРАИНА ДАЛАЛАРЫНДА». **«Пионер»** көндезге 1 сәгатьтә—«РУСЛАН һәм ЛЮДМИЛА», көндез һәм кич — «ДУСЛЫК». **«Чаткы»** көндез — «ДУСЛАР», кич—«АЛТЫН ТАУЛАР».

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ 1096 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 607